ГЛАВА МАЛОМЕМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛ РАЙОНЫ
КЕЧЕ МӘМИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛАГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

17.11.2023 г. Кече Мәми авылы № 4

Гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль
районының Кече Мәми авылында
гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кече Мәми авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР КЫЛАМ:

1. 2023 елның 27 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Кече Мәми авылы, Үзәк урамы, 2а нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кече Мәми авыл җирлеге Кече Мәми авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. 2023 елның 28 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Кече Мәми авылы, Үзәк урамы, 2а нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кече Мәми авыл җирлеге Кече Мәми авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.

3. 2023 елның 29 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка Кече Мәми авылы, Үзәк урамы, 2а нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Кече Мәми авыл җирлеге Кече Мәми авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының яшәү урыны буенча Кече Мәми авыл җирлеге Кече Мәми

авылы территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм жирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

*а) җирлек территориясен тозекләндерүне оештыру:*

- Кече Меми авылында материаллар сатып алып, урам яктыртуын ремонтлау;
- территорияне санкцияләнмәгән чүплекләрдән чистарту;
- Кече Мәми авылы территориясен тоту;

*б) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:*

- авыл җирлеге чикләрендәге автомобиль юлларын карап тору;

*в) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту:*

- зиратны материаллар алу белән чистарту.

*г) җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:*

- материаллар сатып алып суүткәргеч челтәрләрен монтажлау.

« РИЗА»                                                    «КАРШЫ»

5. « Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кече Мәми  авылында гражданнар җыенын билгеләү турында» Кайбыч муниципаль районы Кече Мәми авыл җирлеге башлыгының 2023 елның 13 ноябрендәге 1 номерлы карарын юкка чыгарырга.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кече Мәми  авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга һәм  «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru),  Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Кече Мәми  авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Кайбыч муниципаль районы**
**Кече Мәми  авыл җирлеге башлыгы**                    **Е.Н. Алексеева**